

Әле генә Татарстаннын Әлмәт театры яна спектакльләре белән Саранскта булып киттеләр. Милли  театрыбызда татар телендә балалар очен куелган “Шvрәле” спектакль кvрсәттеләр, шул ук кичтә тамашачылар бик кызыклы концерт карадылар. Ә икенче конне Аяз Гыйләжевнын  “Кар астында кайнар чишмә” пьессасы буенча куелган «Мәхәббәткә яше-карты буйсына» (“Любви все возрасты покорны”) дигән  спектаклны карарга Саранск шәһәре, Ромодан, Ләмберә, Рузаевка районнарында яшәvче татарлар жыелды. (Кызганычка каршы, ерак районнардан килә алмадылар). Минзәләлеләр Ләмберәдә  дә булдылар.        Әлмәт театры безгә оченче ел рәттән килә инде. Һәр ел янадан-яна кызыклы спектакльләр һәм концертлар алып килә. Мордовия татарларына чын бәйрәм ясыйлар. Без аларны якын ыруларны, дусларны кебек коттек. Залда бер буш урын юк иде. Кайбер артистларны таныйбыз да, яшьләребез  бер-берсе белән аралашалар да.Беренче конге концерт бик ошаганга кvрә, ботен тамашачылар спектакльга да билетлар алып килгәннәр. Концертта булганнар: “Кvптән шундый кvнелгә якын чарада булырга тели идек. Искиткеч матур жырлар, кызыклы монологлар, колкеле мәзәкләр, татар биюләре кәефләрне кvтәрде, кvнелдә матур хисләр уятты, йорәкләрне шатландырды. Артистларнын талантларына шаккаттык. Рәхәт эчендә кичебезне уздырдык. Бик зур рәхмәт әйтәсе килә аларга”, - дип, мактап сойләделәр.

Аяз Гыйләжевнын “Кар астында кайнар чишмә” пьесасы буыннар арасындагы мәнгелек аталар һәм балалар проблемасын кvтәрә.

Яна замана балалары vстергәнбез, алар гореф-гадәтләрне чvпкә дә куймыйлар, безне дә анламыйлар дигән фикергә киләләр. Баш геройлар Тәскирә белән Әбvзәр дә сvзләре, уйлары, тормышта куйган максатлары, тормыш кагыйдәләре берторле булып чыга. Якты эпизод: Әбvзәрнен кулыннан ачуланган вакытта тартып алган  театр билетларын Кәримжан кесәсеннән таба, юкка югалмасыннар дип спектакльга баралар, икәvләшеп тонге шәһәрдән колешә-колешә  кайталар. Ник бер шәһәрдә яшәп, бер-беребезне иртәрәк очратмадык  икән дип монланалар. Алар - бер берсенә гайшыйк булалар. Кочакланышып торганда, балалары аларны кvрә... Шулай итеп, яшьләр ике ялгыз йорәкне бергә куша.

Шундый эчтәлекле спектакльны карап, вакыт узганын да тоймый калдык. Артистларнын

һәр хәрәкәтен, сулышын  сизеп утырдык. Матур жырларын тынсыз калып тынладык. Кайбер урыннарда елап та алдык, кайбер жирләрдә эчебезне тотып рәхәтләнеп колдек. Олыларнын мәхәббәтен бик тиз кабул иттек кебек, ә яшьләрне анлап та бетерә алмадык шикелле тоелды. (Без, олкәннәр, заманача тормыйбыз, ахрысы). Минемчә, һәр тамашачы сәхнәдә барган вакыйгаларны йорәге аша vткәрде. Артистлар шундый оста, тырышып рольләрен башкардылар, әйтерсен сәхнәдә дә тvгел, ә чын тормыш вакыйгаларында катнашасын. Әлбәттә, шундый спектакльләр тормышта булган хәлләрне дә яхшырак тошенергә ярдәм итә, зиһенебезне дә арттыра,  дип уйлыйм мин. Артистларнын уйнавы йорәкләребезнен нечкә, яшеренгән кылларын тибрәтте, уятты. Кvнелләребездә матур, ямьле хисләр тудырган очен бик зур рәхмәт аларга! Әнисәне Татарстаннын атказанган артисты Вәлиева Голнара Арсенал кызы башкарды, Кәримжанны - Эдуард Латыйпов, Әбvзәрне - Әхмәдиев Рифат Хәсән улы, Тәскирәне – Нуриева Ләйсән Рафаэль кызы уйнады. Яшь остакайлар да тәжрибәле артистлардан калышмадылар.
Туган телебездә, татар телебездә караган спектакльләр, концертлар  рухыбызны кvтәрә, кvнелләргә ямь ости. Әлмәт театрынын режиссерларына, постановщикларына, гастрольны оештыручыларга - барысына да тамашачылардан зур рәхмәт!
Спектакль тәмамлангач, рәхмәтебезне белдерер очен артистлар янына кердек. Алар белән сойләштек.Тормышта да бигрәк матур кешеләр икәннекләрен белдек. Киләсе елга да Мордовия татарлары, театр яратучылар котә Сезне!

**Рауза Юмаева**